



***“Кеше булыр өчен  гәүдә булу гына  җитми, гыйлем булу да шарттыр. Гыйлем вә тәрбия орлыкларын хәзер ихлас вә мәхәббәт илә чәчсәгез, киләчәктә файдалы җимешләрен дә үзегез җыярсыз”.(Ризаэддин Фәхреддин)***



. **ТЭЙК ОФ –ТАЧ ДАУН**

- Иясе дә, хәбәре дә булган җөмлә кушма җөмлә була.
- Ике яки  берничә хәбәрлектән торган җөмлә кушма җөмлә була.
- Тезмә кушма җөмләдә  гади җөмләләр үзара көттеру паузасы  ярдәмендә теркәлә.
- Тезмә кушма җөмләдә  бәйләүче чара булып санау интонациясе килә ала.
- Тезмә кушма җөмләдә гади җөмләләр арасына   сызык  куела ала.
- Тезмә кушма җөмләдә  бәйләүче чара булып ияртүче теркәгечләр катнаша.





**Яфраклар коелган, шуңа күрә агачлар моңсуланып калган.**

# Иярчен җөмләләр

Аналитик

Синтетитик




# Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре

# Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре



***Иярчен хәл җөмләләр***

- вакыт җөмлә
- урын җөмлә
- рәвеш җөмлә
- күләм җөмлә
- кире җөмлә
- шарт җөмлә
- максат җөмлә
- сәбәп җөмлә

# Иярченле кушма җөмләдә бәйләү чаралары

**Аналитик чаралар**

- Мөнәсәбәтле сүзләр
- Ияртүче теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр
- Көттерү интонациясе

**Синтетик чаралар**

- Кушымчалар
- Бәйлек һәм бәйлек сүзләр
- Янәшәлек

# Сынамышлар.

- Көз озын килсә,  яз соң килер.
- Имәндә чикләвек күп булса,  кыш салкын килә.
- Суган кабыгы калын булса,    кыш салкын була.
- Әгәр беренче кар коры булса,  җәй яхшы булыр, ашлык уңар.

# Мәкальләр.

- Кем эшләми, шул ашамый.
- Кемнең эше бар, шуның ашы бар
- Кем үзен тыйнак тота, аны һәрчак хөрмәт итәләр.
- Ни чәчсәң, шуны урырсың.

**Икенче ноябрь.**

**Сыйныф эше.**

**Иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре.**

# Иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре

**Синтетик иярченле кушма җөмлә**

1.(…-са), [ ].

2.(…-ү белән), [ ].

3.[…(…-ү белән)…].

4. [… (…не)… ].

5. ( ) [ ].

**Аналитик иярченле кушма җөмлә**

1. [ ], (чөнки…).
2. 2. ( ), [шуңа күрә…].

3. [ ], (әйтерсең…).

4.(кайда…), [шунда…].

5. [… шул]: ( ).

6. [ ]: ( ).

| | | |
|---|---|---|
| **Табигать** | **тиңсез** | **хәзинә** |
| **саклау** | **чишмәләр** | **кадер** |
| **юкка чыгу** | **матурлык** | **кошлар** |

**“ТИК-ТЭК-ТОУ”**



**Бер якта – җөмләләр, икенче якта шул җөмләләрнең схемалары бирелгән. Дөрес җавапны табып язарга кирәк.**

| | |
|---|---|
| 1. Мине сөйсәң, оныт туганыңны | (...-сәм да), [ ] |
| 2. Егылсам да, антым хәтеремдә һәркайчан. | (...-са да), [ ] |
| 3. Яратмаса, кыен түгел, төзәтү бу хатаны | (...-сәң), [ ] |
| 4. Безне язмыш аерса да, дуслыкны, бәгърем, онытма. | (...-сак та...), [ ] |
| 5. Кайтмасак та яныгызга, сез безнең йөрәкләрдә. | (...-са), [ ] |

# Җавап:


1- (...-сәң), [ ]

2- (...-сам да), [ ]

3- (...-са), [ ]

4- (...-са да), [ ]

5- (...-сак та...), [ ]



# Күнегүләр:

Нокталар урынына тиешле җөмләне куеп, кушма җөмләләр төзегез.

Кем намус белән хезмәт итә, … .

Иң әһәмиятлесе: … .

Шунысы яхшы: … .

Аңлашыла ки, … .

Җөмләләр: *сезнең сәламәт булуыгыз; сез бу сорауга җавап бирә алмыйсыз; шул зур хөрмәткә ия була; безгә мәктәп бик якын.*

# Өй эше:

“Табигать ул – үзебез!” дигән темага иярченле кушма җөмләләр төзеп, кечкенә күләмле инша язарга



# Җөмлә төрләрен әйтегез.

- Кеше булыр өчен иң кирәкле шарт шул: гыйлемле, бәхетле, тәүфыйклы булу.
- Аңлашыла: без Ризаэтдин Фәхретдин сүзләрен укыдык.
- Килер шундый көн: без татар халкының белемне кешеләрен тагында күбрәк белербез.



- Тикшерәбез:

1. Аналитик хәбәр җөмлә
2. Аналитик ия җөмлә
3. Аналитик аергыч җөмлә.